КҮҢЕЛДӘ САКЛАНЫР

Лениногорскида Россия Герое Дамир Исламовны соңгы юлга озаттылар

> 2

АВЫЛ ИМАМЫ

«ВТ» укучыларының саладагы дин әһелләре турында язмалары

> 3

АНА ЙӨРӘГЕ

Егерме ел эчендә җиде баласының бишесен һәм ире Миңһаҗны югалткан ул

> 4

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

«Табигатьтә берни үзгәрмәгән. Җанда гына...»

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 44 (28817) | Чәршәмбе | 30 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ҮЗ КӨЕМӘ, ҮЗ ИЛЕМДӘ

Россия халкының яртысыннан артыгы быелгы җәйге ялларын ил буенча сәяхәт итеп уздырырга ниятли. «Tvil.ru» кунакханәләр һәм фатирлар броньлау сервисы уздырган сораштыру нәтиҗәләренә караганда, читтә ял итүне халыкның нибары 6 проценты гына сайлаган.

Марат Хәбибуллин коллажы

Кыскасы, чит илләрдә ял итеп күнеккән туристлар инде берничә ел дәвамында Россиянең эчке туризмы үсешенә үз өлешләрен кертә. Туризм буенча федераль агентлык мәгълүматларына караганда, узган ел ялларын ил территориясеннән чыкмый гына уздыручыларның саны 56 миллионга җиткән. Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко сүзләренчә, пандемиягә кадәрге чор белән чагыштырганда, 2021 елда илдәге туристлык тармагы 87 процентка торгызылган. Бу үсешне ул нәкъ менә ил халкының эчке туризмга өстенлек бирүенә бәйләп аңлата.

Татарстанга килгәндә, узган елгы туристик сезонда республика ял итүчеләр саны буенча Россия күләмендә беренче унлыкка кергән иде.

Быел күпме кунак көтәсе?

Җәй айлары турында фаразларга иртәрәк, шуңа да без Казан һәм Татарстан кунакханәләре ассоциациясенең башкарма директоры Александра Юшутинадан май бәйрәмнәренә ниятләре турында сораштык.

– Соңгы ике-өч елда алдан фаразлау бик кыенлашты. Башта без моны пандемиягә бәйләдек, хәзер исә илдәге катлаулы вазгыятьнең тәэсире сизелә. Кешеләр ялларын алдан планлаштыруга бик сак карый. Әйтик, элегрәк кунакларыбыз ике-өч атна алдан ук сөйләшеп куйса, хәзер яшәр өчен урынны ике-өч көн кала гына белешәләр. Ягъни алдан броньлау шактый кимеде, – диде ул безгә. – Узган елгы май бәйрәмнәренә бу вакытта республика кунакханәләренең 60–80 проценты инде буш түгел иде. Быел бу сан 20–50 процентны гына тәшкил итә. Ләкин ялларга таба бу хәл үзгәрер дип уйлыйм.

Туризм буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Сергей Ивановның май бәйрәмнәрендә кунакханәләрнең тулы булачагына шиге юк:

– Нәкъ узган елгы кебек, быелгы май бәйрәмнәрендә дә республика кунакханәләре 100 процентка тулы булыр дип уйлыйм. Ләкин мәсьәләнең икенче ягы бар: быел без узган елгыга караганда азрак ял итәбез. Ял көннәре өчәр-өчәр итеп икегә бүленгән, шуңа да туристлар саны азрак булырга мөмкин, – дигән ул «ТАСС» мәгълүмат агентлыгына.

Комитет җитәкчесе республикада быел 15 яңа глэмпинг (ягъни уңайлыклы палатка, йорт) барлыкка киләчәген дә әйткән. Шулай итеп, аларның санын ике мәртәбә арттырырга исәплиләр. «Гламур» палаткаларны хәзер Татарстанның төрле почмакларында табып, яшәгән җиреңнән артык ерак китми генә урман ялыннан ләззәтләнеп булачак.

Зөя утрау-шәһәрчеге музей-тыюлыгының туристлык бүлеге исә быелгы сезонда кунаклар санын ким дигәндә 10–15 процентка арттырырга һәм бу эшне инде хәзердән башларга ниятли.

– Узган елның маеннан сентябрь аена кадәр без барлыгы 650 меңнән артык турист кабул иттек. Быел исә туристлар агымын тагын да арттырырга өметләнәбез, – диде безгә туристлык бүлегенең директор урынбасары Мария Хитиева.

Безгә кая барырга?

Рәхәт, күңелле итеп ял итәрлек урыннар үзебездә – Татарстанда да җитәрлек. Без бу турыда инде беренче тапкыр гына язмыйбыз. Алар күп һәм төрле. Тарих эзләре сакланган урыннар да, заманча итеп ясалганнары да, теләсә нинди калынлыктагы кесә өчен бара торганнары да – бары да бар, күрә генә бел. Машинаң булмау да киртә түгел – су транспорты да, җир өстеннән җилдерүче автобуслар да йөреп тора.

Без Казан һәм Татарстанның үзенчәлекле урыннары белән «Казань интересная» блогы аша таныштыручы Русина Семененко белән аралаштык. Ул республика халкына да, килгән кунакларга да һичшиксез барып күрергә кирәкле җиде урын турында сөйләде.

Ахыры 4 нче биттә >

Армия кичектерелә

Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә эшләүче компанияләр белгечләре өчен армия хезмәтен кичектереп тору кагыйдәләре расланган. Хөкүмәт Рәисе Михаил Мишустин бу җәһәттән карарга кул куйган. Сүз югары белемгә ия булып, IT-компанияләрдә кимендә бер ел эшләүче 27 яшькә кадәрге егетләр турында бара. Бу кагыйдәләр бер елдан кимрәк эш стажына ия булган белгечләргә дә кагыла. Әмма бер шарт белән: алар үз вазыйфасына билгеләнгәнче бер ел элегрәк вуз тәмамлаган булырга тиеш.

Яшь белгечләре өчен армия хезмәтен кичектерергә теләүче компанияләр, аларның исемлеген булдырып, 1 майга кадәр Россия Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгына юлларга тиеш. Шуннан соң гомумиләштерелгән исемлек Оборона министрлыгына җибәреләчәк.

Карарда шулай ук армия сафларына баруны кичектерүгә дәгъва кылу мөмкинлеге биргән вуз белгечлекләре һәм юнәлешләре расланган. Алар арасында математика, гамәли информатика, радиотехника, робот техникасы, авиатөзелеш, кораблар төзү белгечлекләре – барлыгы 60 юнәлеш бар.

Уртача эш хакы – 46300 сум

Татарстанда эшләүче халыкның санын һәм уртача хезмәт хакын исәпләп чыгарганнар. «Татарстанстат»ның гыйнвар ае мәгълүматларына караганда, республикада барлык эшләүче кешеләр саны – 1,244 миллион чамасы. Төбәктә яшәүчеләрнең күбесе (251,3 мең кеше) эшкәртү производстволарында хезмәт куя. Мәгариф өлкәсендә – 147 мең, сәүдә – 139,8 мең, транспортта – 107,6 мең, сәламәтлек саклау өлкәсендә 97,6 мең кеше эшли. Ә менә кунакханә бизнесы (19,8 мең кеше), су белән тәэмин итү (14,4 мең) кебек өлкәләргә җәлеп ителүчеләр саны шактый аз.

Татарстанда уртача эш хакы 46,3 мең сум тәшкил итә. Иң күп хезмәт хакын казылма байлыклар чыгару өлкәсендә (72,7 мең сум), мәгълүмат (67,3 мең сум), финанс һәм иминиятләштерү өлкәсендә (60,9 мең сум) эшләүчеләр ала.

Чирләүчеләр кимегән

Соңгы мәгълүматларга караганда, Россиядә 12 гыйнвардан соң тәүге тапкыр бер көн эчендә коронавирус йоктыручыларның 20 меңнән кимрәк булуы ачыкланган.

Шул ук вакытта чир иярткүчеләрне хастаханәгә салу очраклары бер тәүлеккә 4932гә (179,9%) җиткән. Бу – алдагы көн (1762 очрак) белән чагыштырганда, күпкә зур күрсәткеч. Хастаханәгә озатылучылар саны 78 төбәктә арткан. Дүртесендә – кимегән, 3 төбәктәге вазгыять үзгәрешсез калган. Коронавирустан савыгучыларга килгәндә, аларның саны тәүлегенә 47229га арткан. Кызганыч ки, үлүчеләр саны да ишәйгән: бер тәүлек эчендә 339 кеше вафат булган. Алдагы көнне 335 үлем-китем очрагы теркәлгән.

Майда җәй җитә

Татарстанда майның 20ләрендә үк җәй җитәргә мөмкин. КФУ Экология һәм табигатьтән файдалану институтының метеорология кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев шулай дип фаразлый.

Аның әйтүенчә, бу чорда һава температурасы нормадан якынча 1 градуска югарырак булырга мөмкин. Июль һәм август айларында күрсәткечләрнең нормадан тайпылмавы көтелә. Ә июльдә гадәттәгедән салкынчарак булачак. «Әмма бу – уртача күрсәткеч, һава температурасы нормага сыешмаячак, дигәнне аңлатмый. Быел җәйнең гадәттәгечә килүе көтелә, шул исәптән эссе көннәр дә булачак», – дигән Тимур Әүхәдиев.

Моңа кадәр Татарстан Гидрометеоүзәгеннән хәбәр ителгәнчә, апрель аенда республикада яшәүчеләрне аномаль җылы һава көтә. Башлангыч фаразларга караганда, инде бу атна азагында ук һава температурасы +5...+10 градуска кадәр җылыначак. Хәтта төнлә дә җылы: 0...+5 градус.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Төзелеш

Өйдең – өй, кактың – чөй

ИПОТЕКА һӘМ ФАТИР БӘЯЛӘРЕНӘ БӘЙЛЕ ВАЗГЫЯТЬ

Ил-көндәге яңалыклар төзелеш тармагына да тәэсир итми калмый, билгеле. Моңа карап кына йортларны салмыйча, яңа фатирларны ияләренә тапшырмыйча да яшәп булмый.

Россия Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән тармакка ярдәм итү юнәлешендә нәрсә эшли? Борчыган төп сорауларга тармак җитәкчесе җавап бирә.

Торак мәсьәләсе

Мәгълүм булганча, 2020 ел азагында металл бәясе арту йорт бәяләренең күккә терәлүенә китерде. Хәзерге вакытта төзелеш кирәк-яракларына бәя күтәрелүен йөгәнләп торып була дип ышандыралар. Шулай да бу яңа төзелеп килүче йортларның квадрат метры бәясе үзгәрүенә китермәсме? Россия төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Ирек Фәйзуллин сүзләренчә, монысы инде аерым предприятиеләрнең коммерциячел эшчәнлегенә һәм аларның базар кагыйдәләре буенча уйнавына да бәйле. Министр әйтүенчә, федераль Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә төзелеш тармагына ярдәм итү чаралары турында әледән-әле фикер алышып торалар. «Әлегә комплекслы чаралар бар, адымлап барысы да хәл ителер», – ди Ирек Фәйзуллин.

Февраль аенда ипотека ставкасы 20 процентка җиткәннән соң, ил Президенты Владимир Путин 1 апрельдән яңа төзелә торган йортлар өчен ташламалы ипотека ставкасын 12 проценттан да арттырмаска кушты. Ирек Фәйзуллин да моның әһәмиятле яңалык булуын искәртә.

– Ипотека кредитларын рәсмиләштерүчеләр һәм аларны бирү саны көннән-көн арта, – ди министр. – Башкала төбәкләре (столичные регионы) өчен кредит күләме 12 млн сумга кадәр тәшкил итәчәк. Ә калган төбәкләрдә 6 млн сумнан артмаячак. Бу да үз нәтиҗәсен бирә. Ташламалы ипотека программасын финанслау буенча тармак министрлыгының матди чаралары бар, тиешле үзгәрешләр кертеләчәк.

Ирек Фәйзуллин искәрткәнчә, хәзергә төп максат – гамәлгә ашырыла торган программаларны туктатмау. Алар барысы да 2022 ел бюджетына кертелгән.

Торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләсе

– Хәзер төзелеш тармагы өчен рәхәт вакыт түгел, әмма Хөкүмәтнең бу юнәлешкә игътибар белән каравы һәм ярдәм итәргә әзер булуы әйбәт. Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык тармакларында 12 млн кеше эшли, – ди Дәүләт Думасының Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе Сергей Пахомов.

Хәзер күпләрне коммуналь хезмәтләр өчен тарифларның арту-артмау мәсьәләсе дә борчый. Бу җәһәттән Пахомов та, Фәйзуллин да борчылмаска куша.

– Тарифларны индексацияләү Хөкүмәтнең ноябрьдәге карарларында теркәлгән һәм без 1 июльдән соң тарифларны арттырырга җыенмыйбыз. Мондый бурыч юк, – диде Ирек Фәйзуллин.

Сергей Пахомов әйтүенчә, тарифларны арттыру турында иң соңгы чиратта гына уйларга мөмкин. «Әгәр без аларны арттырабыз икән, халыкка ярдәм итү өчен дә күбрәк акча кирәк булачак», – диде ул. Комитет җитәкчесе сүзләренә караганда, хәзерге вакытта гражданнарга да, гомумән, тармакка да ярдәм итүнең төрле юллары карала.

Сүзгә-сүз

Сергей ШОЙГУ, Россия оборона министры:

Хәрби хезмәткә алынучы егетләр берниндә «кайнар нокта»ларга да җибәрелмәячәк. Узган елгы язгы чакырылышта хәрби хезмәткә алынучылар, хезмәт итү вакыты тәмамлану белән, запаска җибәрелеп, өйләренә кайтарылачак.

(29 мартта селектор киңәшмәсендә әйткән сүзләре)

РОССИЯНЕҢ ИҢ УҢЫШЛЫ ТӨБӘКЛӘРЕ

Гражданлык җәмгыятен үстерү фонды (ФоРГО) илнең социаль-икътисади яктан уңышка ирешкән төбәкләрен ачыклаган. Исемлекне төзегәндә, белгечләр төбәктәге уртача хезмәт хакы, яшәү минимумы күләменә, сәнәгать җитештерүчәнлеге индексына һәм башкаларга игътибар иткән.

1............Ямал-Ненец автономияле округы
2............Мәскәү
3............Ханты-Манси автономияле округы
4............Санкт-Петербург
5............**Татарстан**
...
34.........Калининград өлкәсе
35.........Чукотка автономияле округы





Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

СӨЙЛӘШҮНЕҢ НӘТИҖӘСЕ БУЛЫРМЫ?

Дөнья сәясәтенең үзәк вакыйгасы булып, әлбәттә, бу көннәрдә үтүче Россия – Украина сөйләшүләре тора. Әрдоганның каршы торучы якларны төрек мәйданына тартып китерүе берникадәр өметләр уята, чөнки сәясәттә чаларган Әнкара лидеры Путинга да, Зеленскийга да күпмедер дәрәҗәдә йогынтыга ия. Ул йогынтының әһәмиятен күпертергә кирәкми, билгеле. Ике якның да компромиссларга юл куймый торган үз принципиаль таләпләре бар. Кәгазьдә генә теләсә кайсы ике ноктаны бер туры белән тоташтырып була ул. Сәясәттә андый турылар, кызганыч, юк шул. Ике илнең дә вәкаләтле делегацияләре дүшәмбе көнне Төркиягә килделәр инде. Төрекләр алар өчен госманлы солтаннары сарае булган Долмабахчә музеен сөйләшү урыны итеп әзерләп куйдылар. Солтан Габделмәҗид I моннан 180 елга якын элек төзеткән затлы сарай яңадан дәүләткүләм сөйләшүләр урынына әверелә. Сишәмбе иртәсендә анда сөйләшүләр башланды. Бу юлы арбитр ролен Әрдоган үз өстенә ала. Ул сөйләшүләр алдыннан делегацияләр вәкилләре белән күрешеп, әлеге очрашуны «бөтен дөньяга өмет бирә» дип атады һәм аның нәтиҗәле булуын теләде.

Үткән атнада булган Куркынычсызлык советында Путин теле белән украиннарның сөйләшүләрдә акрын кыймылдаулары сызланып билгеләп үтелде. Киев ягы үзен җиңеп баручылар кебек тота, Мәскәү дә үзе турында шундый ук фикердә. Әмма актив хәрби хәрәкәтләрне туктату гына ике як өчен дә җиңү була алыр иде. Долмабахчә сараенда ахыргы килешүгә имза салынмас салынуын. Утны туктату турында игълан итеп булса, зур уңышка ирешелер иде. Зур килешү бары тик ике Президентның бер өстәл янына утыруы вакытында гына була ала. Әрдоган андый очрашуны уздырырга да әзер булуларын белдерде.

Сөйләшүләрнең нәтиҗәсе турында сүз алып барып булмый әле. Әрдоган никадәр генә оста дипломат булмасын, каршы якларның амбицияләрен үзгәртә алмаячак. Тик шулай да аның Путин белән байтак килешүләргә уртак имзалар салганы бар. Киевка да төрек йогынтысы көчле. Шулай булгач, алга таба адымнар ясалмый калмас дип өметләник.

Дөньякүләм икенче зур вакыйга Кытай мәйданында баш калкытты. Көтмәгәндә, дөнья халыклары коронавирус куркынычын онытып барган бер чакта, Шанхайда соңгы ике елдагы иң масштаблы локдаун игълан ителде. Кешеләргә йортларыннан чыгарга рөхсәт юк, офислар, кибетләр һәм рестораннар ябыла. 26 миллионнан артык кеше яшәгән шәһәр тынып кала. Кытайда һәрвакыт кырыс көрәшәләр пандемиягә каршы, әмма күрәбез: һаман да вирус зәхмәтеннән котыла алмыйлар. Югыйсә вакциналар да җитәрлек инде. Мөгаен, төп куркыныч ковид тарафыннан түгел, ә икътисад тарафыннан яный торгандыр. Ике ай рәттән инде Кытайдан капитал кача. Моны Тайвань тирәсендәге киеренкелек белән аңлаталар. Вәләкин киеренкелек чин икътисад гигантларының дефолты якынаю сәбәпле туа кебек. Коронавирус һәм Тайвань проблемалары гигантларның түнүен аңлату өчен сылтау гына шикелле тоела.

Россиядә

ТЕХНОЛОГИК ЧИШЕЛЕШЛӘР ЭЗЛӘГӘНДӘ

Россиянең эчке тормышында: икътисадында да, социаль өлкәдә дә Украина конфликты, тирән буразна итеп, эз сызып бара. Газ экспортына сумнар белән түләү проблемасы бүген үк зур дивар булып калкып чыкты инде. Зур җиделек илләре принципиаль рәвештә сумга каршы, Россия исә газ кранын ябабыз дип тора. Ике як өчен дә бик авыр мәсьәлә килеп туды, әмма чишелеше бар аның. Зур җиделек илләреннән бары тик бишесе генә Россия газын ала. Алар арасыннан бары тик Германия генә Себер ягулыгына нык бәйләнгән. Болар аяк терәп торырлар, әлбәттә. Россия газын алучы дистәләгән ваграк дәүләт бар әле анда. Болгария һәм Сербия белән Россиянең сумнарда сәүдә итешү турында килешүләре бар. Венгрия түләргә әзер. Менә шул өч ил, газ сатып алу күләмен берничә тапкыр арттырып, башка илләргә экспортлый алалар. Төркия Евросоюзга керми, ул – «дус ил», аңа Мәскәү долларда да сата, Әнкара сумга алырга да күптән риза инде. Төрекләрнең Европага Россия газын реэкспортлавы байтактан бара. Башка илләр өлешчә киметерләр Себер газын ягуны, өлешчә реэкспорттан валютага алырлар. «Бүре дә тук, сарыклар да исән» кагыйдәсе файдаланылыр, мөгаен. Бу юлларның авторы шулай уйлый. Әмма киләчәктә Россия өчен Европа базарын тулысынча югалтуга китерергә мөмкин бу хәл.

Россия өчен куркыныч тагын бер яктан яный. Көннән-көн комплектлаучы детальләр һәм технологик җиһазлар кытлыгы көчәячәк. Аларны алыштыру өчен, дәүләт машинасы, чиновниклар аппараты, бизнес һәм инженер-техник персонал бердәм рәвештә кулга-кул тотынып эш иткәндә дә күп вакыт кирәк. Вакыт исә кысынкы. Дус илләр белән сәүдәгә дә өметләнеп бетәргә ярамый, чөнки Вашингтон администрациясе ул илләрнең бизнесына, Россиягә җиһазлар һәм технологияләр саткан өчен, икенчел санкцияләр белән яный. Ни генә дип әйтсәң дә, Америка санкцияләреннән куркалар әле дөньяда. Россия үзе дә әлегә кадәр Американың башка илләргә керткән санкцияләрен төгәл үтәргә тырышты.

Товар алмашуның контрабанда ысулына якын юллары файдаланылыр, мөгаен. Иран, мәсәлән, файдаланды алардан. Илгә хәтта долларларны да контрабанда ысулы белән керттеләр. Тулы изоляция юк ул бер илгә каршы да.

Гадирәк товарларны җитештерүне үзебездә җайга салу озак булмас. Әйтик, ак кәгазь җитештерү катлаулы мәсьәлә түгел. Башка көнкүреш вак-төякләрен ясауны җайга салу да елларга ук сузылмас. Катлаулы технологияләр белән эш авыррак. Зур предприятиеләрнең туктап калуына, вакытлыча эшсезлеккә, социаль киеренкелекнең артуына түзәргә туры киләчәк. Белгечләр әйтүенчә, катлаулы технологик чишелешләр өчен 3–5 ел вакыт кирәк булачак. Киев белән уртак килешүне имзалап булса, санкцияләр йомшатылыр дигән өмет бар. Килеп туган вазгыять Россиянең технологик потенциалын үстерүгә хезмәт итә ала, билгеле, чөнки уянырга мәҗбүр итә. Ни дәрәҗәдә тиз уянабыз һәм аяк киенәбез, анысы үзебездән тора инде.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Хезмәттәшлеккә ачык

Көч-мөмкинлекләрне күрсәтү, тәҗрибә уртаклашу урыны. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шушы көннәрдә Дубайдагы инвестицион форумда катнаша. Форум утырышында республика җитәкчесе махсус кунак буларак чыгыш ясады.

– Форум елдан-ел камилләшә, аның катнашучылары да, шул исәптән Россиядән дә, арта. Татарстан исә бу форумга нигез салынган көннән алып әлегәчә партнеры һәм катнашучысы булып тора, – диде Татарстан Президенты. – Безнең өчен бу – яңа инвестицион мөмкинлекләребезне күрсәтү, тәҗрибә уртаклашу һәм яңа элемтәләр булдыру мәйданчыгы.

Рөстәм Миңнеханов форум кысасында күтәрелгән сорауларның актуальлегенә дә игътибар итте. Алар киләчәк өчен инвестицияләр турында иде. «Ике елдан артык кешелек пандемия шартларында яши. Дөньяви икътисадта да җитди үзгәрешләр бара. Глобаль сәясәтнең өстенлекле юнәлешләренең берсе – икътисадны торгызуга, үсешкә һәм инновацияләргә юнәлгән инвестицияләр», – дип чыгыш ясады республика Президенты.

Рөстәм Миңнеханов республиканың төрле тармаклар буенча алдынгы булуын телгә алды. Инвесторларны кызыксындырырлык чаралар да бар (салым, таможня мөмкинлекләре), цифрлаштыру җәһәтеннән дә күп эш башкарыла. Президент Татарстанның ислам банкы юнәлешен үстерү буенча Россиядә сынау төбәге булуын әйтте.

Рөстәм Миңнеханов Татарстан өчен бу елның истәлекле даталарга бай булуын искә төшерде. Әйтик, май аенда Болгарда ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үтәчәкбез. Меңьеллык тарихлы Казан исә быел «Ислам илләре хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр башкаласы» исеменә лаек булды. Быел ЮНЕСКО комитетының 45 нче сессиясе дә Казанда үтәчәк.

Рөстәм Миңнеханов Татарстанның хезмәттәшлек өчен ачык, яңалыкка кызыксынучан булуын әйтте, форумдагыларны бу сүзләрнең раслыгына инану өчен кунакка чакырды.

КҮҢЕЛЛӘРЕБЕЗДӘ МӘҢГЕГӘ САКЛАНЫР

tatarstan.ru

Батырлык

Лениногорскида Россия Герое Дамир Исламовны соңгы юлга озаттылар. Украинадагы махсус хәрби операциядә гомере өзелгән яшь офицер белән хушлашу шәһәрнең мәдәният йортында узды. Матәм чарасында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм Татарстан хәрби комиссары Сергей Погодин катнашты.

Үзәк хәрби округы гаскәрләре командующие вазыйфаларын башкаручы генерал-майор Рөстәм Миңнекәев, матәм чарасын ачып, Россия армиясенең лаеклы һәм батыр хәрбиләре белән данлыклы булуын билгеләп үтте.

– Килеп туган катлаулы шартларда генераллар, офицер һәм солдатлар арасында аерма була алмый. Ватанны саклауда без барыбыз да бертигез. Кызганычка, иң яхшылар һәлак була, чөнки алар беркайчан да иптәшләре артына яшеренми. Өлкән лейтенант Дамир Исламов җитәкчелегендәге танк экипажы 4 танкны юк итә. Экипажның фидакарьлеге нәтиҗәсендә дошманның һөҗүмен кире кайтаруга ирешелә. Дамир Ватаныбызны саклап һәлак булды. Халык үзенең геройларын онытмаячак.

Үзәк хәрби округының кадрлар бүлеге башлыгы урынбасары Алексей Белоконь, Дамир Исламовка Россия Герое исемен бирү турында Президент Указын укып үткәннән соң, каһарманның әнисе Саҗидә Вәлиәхмәтовага югары дәрәҗәдәге дәүләт бүләген тапшырды.

Һәлак булган геройның әнисе улының каһарманлыгын таныган өчен ил җитәкчелегенә рәхмәт белдерде.

– Мин һәрвакыт үземнең улым белән горурландым һәм һәрвакыт горурланачакмын. Безнең күңелләрдә, дуслары һәм иптәшләренең күңелләрендә мәңгегә сакланачак ул. Ватаныбыз авыр чакта үзенең улларын һәм кызларын югалта. Илне кем дә булса сакларга тиеш, – диде кайгыга баткан ана.

Шуннан соң Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин геройларча һәлак булган егетнең гаиләсенең һәм якыннарының кайгысын уртаклашты.

– Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм республиканың беренче Президенты Минтимер Шәймиев исеменнән һәлак булган егетнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклашырга дип килдем. Бүген Татарстанда дистәләрчә мең кеше сезнең белән бергә хәсрәт утында яна. Тормышка бик нык әзерлекле, намуслы, тәртипле кеше иде. Дәүләт башлыгы аның каһарманлыгын тиешенчә бәяләде. Дамирның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр, – дип мөрәҗәгать итте һәлак булган 26 яшьлек егетнең гаиләсенә Фәрит Мөхәммәтшин.

Фәрит Мөхәммәтшин басым ясап әйткәнчә, күпмилләтле Россиянең беркайчан да кемне дә булса яулап алу теләге булмады. «Без һәрвакыт үзебезне сакладык һәм бүген Украинада яшәүче халыкларны нацизмнан коткаруга ярдәм итәбез, – дип билгеләп үтте ул. – Бу изге миссияне безнең армия, Россия кораллы көчләре башкара, алар зур сугышны булдырмый калу хакына көрәшә. Геройга мәңгелек дан!»

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та үзенең «Телеграм» каналында Дамирның якыннарының кайгысын уртаклашты:

«Лениногорск шәһәрендә туып-үсеп, Казан танк училищесын тәмамлаган өлкән лейтенант Дамир Исламовның туганнарының һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклашам... Аның Ватанга хезмәт итү үрнәге мәңгегә безнең хәтердә калачак», – дип язган ул.

Дамир Исламов Лениногорскида туып-үскән. Казан танк училищесын тәмамлаган. Украинада махсус операция барышында аның экипажы, дошман белән тигезсез сугышка кереп, биш танктан дүртесен юк иткән. Алга таба һөҗүмгә барганда, Дамирның танкы дошман тубыннан шартлаган...

Бу – хәлиткеч этап

Мәскәүдә «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясе Генераль советының халыкара хезмәттәшлек һәм чит илдәге ватандашларга ярдәм итү буенча комиссиясе утырышы узды. Комиссия утырышында партиянең Югары совет әгъзасы, Татарстан төбәк бүлеге секретаре, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

Билгеле булганча, Россия Президенты Владимир Путин йөкләмәсе буенча «Бердәм Россия»нең сайлау алды исемлеге лидерлары партиянең махсус төзелгән комиссияләрен җитәкли. Россия тышкы эшләр министры Сергей Лавров халыкара хезмәттәшлек һәм чит илдәге ватандашларга ярдәм итү комиссиясен җитәкли.

Сергей Лавров ассызыклаганча, безнең ил, Европа һәм бөтен дөнья катлаулы чор кичерә.

– Барлык кыенлыкларга да карамастан, Россия дипломатиясе халыкара аренада ил мәнфәгатьләрен эзлекле һәм ныклы рәвештә яклаячак, Россия гражданнарының һәм чит илдәге ватандашларыбызның тормышын, намусын, иминлеген саклау өчен кулдан килгәннең барысын да эшләячәк, – диде ул.

Россия тышкы эшләр министры шулай ук чит илдә яшәүче ватандашларга һәм рус телле халыкка ярдәм итү өчен яңа чаралар әзерләнгәнен әйтте.

Утырыш нәтиҗәләре турында сөйләгәндә, Фәрит Мөхәммәтшин аның вакытлы булуын ассызыклады.

– Без тулы мәгълүмат алдык, – диде ул. – Сергей Викторович әйткәнчә, бу – цивилизациянең тарихи үсешендә хәлиткеч этап. Бу шартларда безнең төбәкләрдә милләтара тынычлык һәм татулык өчен бергәләп тырышырга кирәк. Россия Президенты алдан күреп кабул иткән карарларга, Кораллы көчләргә теләктәшлек белдерү – болар барысы да зур илне берләштерде. Без бу сәясәтне хуплыйбыз. Татарстан икътисадны тотрыклыландыру, Көнбатыш илләр санкцияләренә каршы тору өчен актив чаралар күрә. Күпмилләтле халык киләчәккә ышаныч белән карый һәм бу процессларның тәмамлануын көтә. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Дәүләт Думасына «Бердәм Россия»дән сайланган депутатлардан ватандашлар белән эшне көчәйтү турында файдалы тәкъдимнәр булды. Утырышта яңгыраган тәкъдимнәр Россиянең барлык субъектларында һәм, аерым алганда, Татарстанда теләктәшлек табачак.

«Бердәм Россия»нең халыкара хезмәттәшлек буенча комиссиясе Европадагы иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләренә мөрәҗәгать белән чыкты. Аны Европадагы барлык илләрдәге җәмәгатьчелеккә җиткерү планлаштырыла, дип хәбәр итә Татарстан Дәүләт Советының матбугат хезмәте.

ЧҮПЛӘМӘСӘҢ ГЕНӘ ЧИСТА

Язгы яңару

Татарстанда 1 апрельдән чистарту икеайлыгы башлана. Шул ук көнне «ЭкоЯз – 2022» бәйгесенә дә старт биреләчәк. Республикакүләм чистарту өмәсен 23 апрельдә үткәрәчәкләр. Бу хакта Хөкүмәт йортында узган очрашуда Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков әйтте.

– Язын кар астыннан ни генә чыкмый! Шуларны тәртипкә китерергә кирәк. Ике ай эчендә республикада яшәүче һәркем үз йорты янәшәсен чистартырга тиеш. Эшләгәннәре бушка китми, алар «ЭкоЯз» бәйгесендә катнаша ала. Аларның «иң-иң»нәрен бүләкләячәкбез дә әле. Бәйге 31 майга кадәр дәвам итәчәк, – ди Александр Шадриков.

Министр чистарту икеайлыгында башкарылачак эшләргә дә тукталды.

– Без тирә-якны чүп-чардан арындырырга тиеш. Күзәтчелек органнары да, экологлар да икеайлыкка әзер. Министрлык, районнарга чыгып та, бу хакта сөйләшүләр уздырды, – ди ул. – Чистарту икеайлыгында гына түгел, гомумән, эшләнәсе эшләр бик күп. «Экология» илкүләм проекты кысасында тормышка ашырылачак эшләр өчен 11,5 млрд сум бүлеп бирелде. Инде хәбәр иткәнебезчә, быелдан сулыкларның һәм елгаларның экологик хәлен тикшерә башлаячакбыз. Иң беренче тәҗрибә Казансуда узачак. Экологлар сулыклардан ел дәвамында 37 мең тапкыр анализ алды. Без сыйфатны һәрчак контрольдә тотабыз.

Министр әйтүенчә, сулыкларга игътибар елдан-ел арта гына. Быел әле су астында калган судноларны да чыгарырга ниятлиләр. Чулманда – 11, Иделдә 64 судно бар икән. Түбән Кама һәм Куйбышев сусаклагычындагы су биеклеге дә һәрдаим күзәтү астында.

– Сусаклагычларда су биеклеге 64 метрга җитү – безнең өчен яхшы күрсәткеч. Әмма кайбер районнарда биеклеге 53,3 метрга күтәрелүгә, халыкны су баса башлый. Димәк, яр буйларында нидер төзегәндә су басу куркынычы исәпкә алынмаган. Әмма моннан чыгу юлларын табарга кирәк. Сулыкларда су биеклеген 64 метр итеп сакларга мөмкинлекләр бар. Без бу турыда Россия күләмендә сөйләшәбез, – ди Александр Шадриков.

Ләм басулары да читтә калмаячак. Аларны чистарту эшләре дәвам итә. Сулыклардан эшкә яраксыз нефть торбаларын чыгара башлаячаклар. «Чиста ил» илкүләм проекты кысасында Самосырово чүплеген рекультивацияләү эшләре дә тиздән тәмамланачак, дип ышандыра министр.

Александр Шадриков әйтүенчә, чистарту икеайлыгы башлангач, тимер юллар да тәртипкә китерелә. Узган ел 270 километр ара җыештырылган. Әлеге эш быел да дәвам итәчәк.

– Барлык эшләр республикадагы экологик вазгыятьне яхшырту өчен башкарыла. Елга буйларын ныгыту, агачлар утырту, су станцияләре төзү, чистарту корылмаларын яңарту – барысы да халык өчен эшләнә. Татарстанда яшәүче һәр өченче кеше өмәләрдә катнаша. Узган ел барлык өмәләрдә 1 миллион 200 кеше кулына себерке, тырма алган. Мәктәп укучылары да ярдәм итә. Алар безгә кайда күпме чүплек барын хәбәр итеп, үзләре дә «Мәктәп патруле» дигән бәйгеләрдә катнашалар, – ди Александр Шадриков.

Министр «ЧИСТАБУЛАЧАК» экологик хәрәкәтенең дә чистарту икеайлыгында актив эшләвен әйтеп үтте. Алар мәктәпләргә дәресләр үткәрергә дә бара, халыкны тирә-якны сакларга да өнди. Александр Шадриков, форсаттан файдаланып, экологиягә битараф булмаган актив кешеләргә рәхмәтен җиткерде. «Тәртип бозучыларны күрәсез икән, безгә хәбәр итегез», – диде ул.

Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары, әйләнә-тирәне саклау буенча баш дәүләт инспекторы Айрат Шиһапов сүзләренчә, халык күбрәк тиешсез урындагы чүплекләрдә, калдыклар ташлаган мәйданнарның тулы булуыннан зарлана.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Чистарту икеайлыгында тиешсез урынга ташланган чүпкә тап булабыз. Узган ел шундый 3 мең 857 очрак теркәлде. Шуның 96 процентын юкка чыгардык. Халык чүбен тиешле урынга ташласа иде, – ди ул. – Чүпләмәгән җирдә генә чиста. Әнә шуны онытмыйк. Һәр җирлектә зират, ишегаллары, гараж яннары, күңел ачу, балалар мәйданчыклары тәртиптә булырга тиеш.

Казан шәһәрендә яшәүче 80 яшьлек Сания Курмакаева бер елны да өмәне калдырмый. Үзе яшәгән йортны чәчәккә генә күмеп калмый ул, өмәләрдә дә катнаша. Быел да хәлен белештек. «Яз җитүгә, җыештыра башлаячакмын. Өмәләр башлануга, хәбәр бирегез», – диде ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясенә кандидатлар

ҮЗЕ ДӘ, ӘСӘРЛӘРЕ ДӘ – ПАРАДОКС!

Равил Сабыр – үзенчәлекле каләм иясе. Аның исеме матбугатта беренче мәртәбә үткән гасырның 90 нчы еллар башында күренә башлады. Чаллыда ул чакта «Таң йолдызы» газетасы халык арасында зур популярлык казанды. Бөтен Татарстан буйлап тарала иде, авторлары – татарның иң абруйлы шәхесләре. Шушы газетада күзгә еш күренгән исем – Равил Сабиров.

Үзгәртеп коруга кагылышлы, социалистик җәмгыятьнең «сызлавык»ларын, колхоз строеның кимчелекләрен ачып салган аналитик мәкаләләре чыгып кына тора. Нык куллы, «пешеп» җиткән журналист дип күз алдына китерә идек без авторны. Минзәлә районы Наратлы Кичү авылыннан ул. Бу кеше партком секретаре булып, идеологик эштә «чие» чыккан яисә мәктәптә тарих укытадыр, дип уйлашабыз. Журналист булып китмичә, авылда әрәм булып ята, дип әрнеп сөйләшкәлибез дә хәтта редакциядә. Берзаман билгеле була: Равил Сабиров 10 нчы сыйныф егете икән. Мәктәп баласы безне яңача яшәргә өйрәтә икән бит, көләрсең дә еларсың да. Язу куәсе, фикер йөртүе – дөньяның ачысын-төчесен күргән өлкән кешенеке үзенең – парадокс!

Инде ул еллардан соң шактый вакытлар үтте, Равил язмышына кагылышлы парадоксларны күпләп китерергә мөмкин булыр иде, ярата ул аларны. Кыскача гына әйткәндә, Равил ул – үзе парадокс. Тормышта да, әдәбиятта да дип ачыклык кертеп тә куярга кирәктер.

Равил 1990 елда Казан университетының журналистика факультетына укырга керде, 1991 елда «Хулиган» исемле беренче хикәясе басылып чыкты. Казан, андагы иҗади яшьләр мохите (беренче нәүбәттә Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Фәиз һәм Ләис Зөлкарнәйләрне һ.б. күздә тотам) килеште Равилгә. Студент елларында ук «Идел», «Чаян», «Татарстан яшьләре»ндә хикәяләре басылып торды. Ул – бер дигән хикәяче, драматургиягә керешеп киткәч, бераз ачуланып та йөрдем әле үзенә. Әмма аның табигатенә артистлык оеткысы да мулдан салынган, сөйли башласа, авызына каратып кына тора, һәр хикәяте бер интермедиягә әверелә. Иң кызыгы: ул сөйләгәннәр хәтердә кала. Драматургиягә атлыгып торуы шуннан киләдер инде, югыйсә прозада ул бүген ат уйнаткан әдип булып таныласы иде дә соң. Татарстан Президенты карамагындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе игълан иткән ябык әдәби конкурста «Фәхрине үтереп ташладылар» романы белән катнашып, җиңүчеләр рәтенә керүе – минем бу фикеремнең дөреслегенә тагын бер дәлил.

Равил Сабырны драматург итеп дөньяга чыгарган әсәр, әлбәттә, Фатих Әмирханның «Хәят» әсәренә нигезләнеп, Гаяз Исхакыйның «Татар гакылы» хикәясен кулланып язылган «Яшел һәм кызыл» драмасы булды. Кыюлык дип кабул ителгән әсәрне Чаллы татар дәүләт драма театрында сәхнәгә яшь режиссер Булат Бәдриев 2007 елда куйды. «Хәят» исеме белән куелды ул. Яшьләргә фатиханы театрның баш режиссеры Фаил Ибраһимов бирде. Аның бу гамәле театр сөючеләр тарафыннан мактауга лаек дип табылды.

Авторның мин кулъязма рәвешендә үк укып чыккан иң беренче сәхнә әсәре исә «Земфирәкәй, сылуым, аппагым» драмасы иде. Бу әсәрдә хәзерге көн өчен актуаль проблемалар күтәрелсә дә, 2004 елда уздырылган «Яңа татар пьесасы» бәйгесендә бу иҗат җимеше белән катнашып, Равил Сабыр лауреат исеменә лаек булса да, нигәдер пьеса зур театрлар күзеннән читтәрәк калды. Парадоксмы? Парадокс! Ә менә халык театрлары яратты, чөнки анда пафос юк, кылану юк, ә халык күңеленә бик тә якын, аңлаешлы әрнү, сызлану бар. «Теләк» пьесасында исә («Яңа татар пьесасы – 2007» бәйгесендә җиңгән әсәрләрнең берсе) яшьләрнең тормышны шаяру итеп кабул итүләре, моның көтелмәгән хәлләргә китереп җиткерүе тасвир ителә. Монда «теләк» сүзен төрлечә аңларга була. Теләк – максатка юл, теләк – булдыруга омтылыш, теләк – уен, теләк – азгынлану… Әйтик, уйнап кына башланган эшнең яшь кешене азгынлыкка юл ачуы, намус-вөҗдан мәсьәләләре, аерым хәлләрдә кеше булып калуның никадәр катлаулы һәм авыр икәне күрсәтелә.

Яр Чаллы татар дәүләт драма театры архивыннан

Ә инде Равилне чын драматурглар рәтенә куйган, чын мәгънәсендә киң катлау укучыларга (тамашачыларга) таныткан әсәр – «Абага алмасы ачы була» драмасы. Аның хакында күп язылды, ел саен «Татарстан – Яңа Гасыр» каналыннан күрсәтәләр, ә халык, һаман заллар тутырып, шушы спектакльне карарга театрга килә. Менә сезгә тагын бер парадокс. Хәер, караган саен үзең өчен яңа ачышка ия буласың бу әсәрдә.

Бу спектакльне караганда, берничек тә битараф кала алмыйсың, чөнки монда җәмгыятьнең нинди булуына карамастан, кешенең чынлыгы күрсәтелә. Насыйбулланың чынлыгы аның күңелендә яшерелгән, аның бу чынлыкны берәүгә дә бирәсе килми. Насыйбулла – совет җәмгыяте корбаны, сугышның исән калган корбаны. Сугыштан соң җәмгыять шактый үзгәрсә дә, ул – бүген дә корбан. Чөнки Тахау, Локман, Лариса Мирзагитовналар аны шәхес дип түгел, ә бер җан асраучы дип кабул итәләр. Тагын шушы чынлыкны ачып күрсәтергә бик нык теләгән журналист егет Айбулат та бар әле. Гомере буе паспортсыз яшәгән бабай – журналист өчен зур табыш, әлбәттә. Тик Насыйбулла белән сөйләшү барышында ул шушы чынлыкны күрә һәм аның шуны башкаларга да күрсәтәсе килә. Ә менә күрсәтергә ирек бирмәүләре – анысы инде безнең бүгенге җәмгыятьнең чынлыгы.

Тамашачы, шушыны аңлап, Насыйбулланың гына түгел, безнең барыбызның да фаҗигабезне аңлап тетрәнә. Һәркем үзенең гаиләсендә Насыйбулла булуына ышана башлый, һәм ул чынлыкта да шулай. Азмыни бездә репрессия чорларында кулга алынып кайтмаган, сугыш елларында хәбәрсез югалган кешеләр? Җәмгыятьтәге соңгы үзгәрешләр чорында күпме кеше үз-үзен югалтты?! Бернинди паспорт ярдәмендә дә таба алмадылар үзләрен! Шуңа күрә Насыйбулланың паспорты ул – аның шәхесе, аның чынлыгы. Шуңа күрә аңа бернинди паспорт та, пенсия дә кирәкми.

«Абага алмасы ачы була» – көчле публицистика белән сугарылган бик катлаулы, тирән эчтәлекле драматик повесть. Мондый әйберне сәхнәгә чыгару – бик катлаулы эш. Геройлар өстендә һәрвакыт гильотина пычагын хәтерләткән рәшәткә эленеп тора. Ул теләсә кайчан аларның башларына килеп төшәргә мөмкин. Бу – җәмгыятьнең тотрыксызлыгын, аның һаман да корбаннар эзләвен аңлата торган символ.

Режиссер Фаил Ибраһимов бу драманы юкка гына Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»е белән чагыштырмый торгандыр. «Абага алмасы ачы була» сәхнәгә куелганнан соң, татар әдәбияты, театр сәнгате тагын бер үлемсез геройга баеды, дип ышанасы килә. Ә татар дөньясы тагын бер кабатланмас актерның барлыгына инанды. Ул – Насыйбулла ролен башкарган Рафил Сәгъдуллин, бу спектакльне аннан башка күз алдына китереп булмый.

Аның берничә репликасын тамашачылар дәррәү кул чабулар белән каршы алдылар. Димәк, артист тамашачыны шушы халәткә китереп җиткерә алды. Бу – бик зур осталык сорый торган әйбер. Һәм инде журналист егет Айбулат бу сөйләшүдән соң җәмгыятьнең беркайчан да бу кешеләр, бу корбаннар алдында гафу үтенмәсен аңлап кайтып китә. Насыйбулла бабайга язган хатында ул аның алдында гафу үтенә, ягъни чын шәхескә әйләнә. Шуның белән Айбулат та бу җәмгыятьнең корбанына әверелә, чөнки ул язган мәкаләсен бастырып чыгара алмый… Аңлаган кешегә бик зур гыйбрәт алырга мөмкин бу спектакльдән.

Факил САФИН

Бәйге

ЗИРЕКЛЕНЕҢ ЗИРӘК КЕШЕСЕ

ВТ Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Безнең районда, күрше районнарда, тирә-як авылларда Яңа Чишмә районы мөхтәсибәте Зирекле авылы мәчете имамы Ильяс хәзрәт турында белмәгән кеше юктыр. «Авылдагы рух тотрыклыгы, милли һәм рухи тормышыбызның чыганагы, хәтта татар теле язмышы да имамнарга барып тоташа», – дип бик урынлы әйтелгән. Әлеге фикерне куәтләп, мәчеттә гыйлем алучы урта буын хатын-кызларының фикерен җиткерәсем килә.

«Без, 30–40 яшьлек әниләр, мәчеткә дин сабагына йөрүче 7–8 яшьлек балаларыбыз артыннан Ильяс хәзрәтнең: «Әниләрегез мәчеткә килсен, Коръән укырга өйрәтәм», – дип өндәвенә күнеп, беренче тапкыр мәчет бусагасын атлап кердек. Аллаһ Тәгалә җаныбызга салган фитри иманнарыбыз шул вакыттан бирле терелеп, наданлык караңгылыгыннан чыгып, инде хәзер мәңгелек бәхет чыганагы булган гыйлем, гамәл, зикер, дога, тәсбих, Коръән укымакта яшәп ятабыз. Дәресләр шулкадәр мавыктыргыч, гади, аңлаешлы итеп бара. Ильяс хәзрәткә Аллаһ Тәгалә шундый хикмәт биргән: инде 20 ел белем алсак та, Аллаһ биргән белемне алган саен аласы килеп тора. Аллаһ илчесе Мөхәммәд тә, гомер буе гыйлем алыгыз, дигән бит. Хәзрәтебезгә 2 төркем хатын-кыз җыелдык. Уңайлы булсын өчен «Фатыйма» һәм «Зәйнәп» төркемнәре дип исемнәр дә куштык. 30дан алып 80гә кадәрле Аллаһ коллары, бирелеп, тырышып, елый-елый, Аллаһны танырга, аның исемнәрен, сыйфатларын, дин тарихын, пәйгамбәрләр тарихын өйрәндек. Үзебездә Аллаһ илчесенең үрнәгендә күркәм сыйфатлар тәрбияләргә тырыштык, ата-ана, мөселманнар, күршеләр һәм барлык мәхлукатларның хакларын белдек. Кылган теләсә нинди гамәлебезнең Аллаһ ризалыгын уйлап эшләнгәне генә кыямәт көнне үлчәүгә куелып, безгә файда китерәчәген төшендек», – дип әйтә Фәйрүзә Ислам кызы.

Рухи тормышны җанландыручы хәзрәтебез тумышы белән Чистайдан. Безнең җирлеккә Аллаһ Тәгалә аңа үзе юл күрсәткәндер. Һәркем белә: 1990 нчы еллар – яшьләр өчен бик болгавыр заман, кызлар белән кызлар, шәһәр малайлары белән авыл малайлары, урам белән урам сугышкан вакытлар. Нинди тәрбия чарасы кала? Бары тик кешенең аңына дини тәрбия биреп, үзаңны үстереп була дигән фикерне алга куеп, Чистай шәһәренең Яшел мәчетенә, дин белгече алырга юнәлдем. 1996 елның 27 гыйнварында Ильяс хәзрәт Зирекле агролицеена гарәп теле түгәрәге җитәкчесе булып аяк басты. Җомга көннәрендә сөйләгән вәгазьләр, ата-аналар каршысында ясаган чыгышлар, бәхетсез гаиләнең сәбәпләрен аңлатулар, сабыйлар һәм өлкәннәр күңелендә дымлы җиргә төшкән тәрбия орлыклары булып шытып чыкты. Авыл картлары, бу талантлы, гыйлемле егетне бик тиз күреп алдылар. Мәчеткә имам итеп билгеләделәр. Бер айга килгән егет шул көннән бирле авылыбызның рухи һәм дини тормышы белән яши. Мәчет умарта иле кебек гөж килеп тора.

saby.tatarstan.ru

Мәктәптән соң балалар, Коръән серләренә төшенергә дип, мәчеткә агылалар. Күптән түгел шундый матур күренешкә тап булдым: урам тутырып, башлангычта укучы балалар кайта, шат авазлары ерактан ишетелеп тора. Якынрак килсәм, урталарында – хәзрәт. Аңа ашыга-ашыга яңалыкларын җиткерергә, шатлыкларын бүлешергә, һәрберсе аңа якынаерга тырыша, олы урамнан хәзрәт яши торган тыкрыкка кадәр озаталар. Димәк, авылның киләчәге бар икән әле.

Биш бала әнисе Мөнирә Шакирова хәзрәтебезгә чиксез рәхмәтен белдерә. «Ильяс хәзрәт балаларыбызны дини, әхлакый, җәмгыятебезгә файда китерүчеләр итеп тәрбияләүдә зур эш башкара. Кызларым ифтар мәҗлесләрендә табын әзерләшергә дә булышалар, уңган хуҗабикәләр булырга өйрәнәләр», – ди ул.

Мәчеткә зур хезмәт куеп, капиталь ремонт уздырды. Ярдәмчеләрен дә таба, шул эшне башкарырга дисәң, Татарстан җирендә яшәүче зиреклеләр ярдәм кулы сузарга әзер. Моңлы азан тавышлары яңгыратып, кояш нурларында балкып, мәчетебез әллә каян күренеп тора. Аның янында мәһабәт бина – мәдрәсә дә салдырды. Шунда укулар, ифтар мәҗлесләре гөрләп уза. Хәзердән үк, авыз ачтырырга теләк белдереп, авылдашлар рамазан аеның һәр көнен бүлешеп алды.

Дин сабакларын алу атнаның һәр көнендә оештырыла. Хатын-кызлар, балалар, ак сакаллы бабайлардан алып яшь егетләргә кадәр мәчеткә юнәлә. Чит авыллардан килеп укып йөрүче егетләр дә бихисап, мәдрәсә янында машина куярга урын калмаган көннәр дә күп була. Коръән тәфсире туры эфирдан алып барыла, күпме кеше тыңлый, гыйлемен арттыра. Менә шуларның берсенең фикерләре белән бүлешәсем килә.

Буа районы Яңа Тинчәле авылыннан Сәфинә Алиуллова Ильяс хәзрәт сабаклары турында иптәш кызыннан ишеткән:

– Мәймүнә дустым хәзрәтнең үзләренә үткәргән дәрес видеоларын җибәрә башлады. Минем гарәп сүзләренең әйтелешен төзәтәсем килә иде. Хәзрәтне тыңлаган саен тыңлыйсы килә, бигрәк яхшы, гади итеп аңлата белә. 30 нчы парәнең сүрәләрен аңлатканда, һәр аятьнең тәфсирен сөйләгәндә аның тирән, күпкырлы белемле булуына, үтемле итеп аңлата белүенә сокланам. Үзем өчен бик күп мәгълүмат алдым, хаталарымны да төзәттем дип уйлыйм.

Хәзрәт, Зиреклегә килгәч, матур гаилә корып җибәрде. Хәләл җефете башлангыч сыйныф укытучысы Гөлшат белән 3 бала үстерәләр. Үрнәк гаилә! Малае югары уку йортында, кызы хатын-кыз өчен кирәкле булган аш-су пешерү серләренә өйрәтә торган уку йортында, кечкенә малайлары 6 нчы сыйныфта укый. Хәзрәт булгач, йомыш белән дә, киңәш сорап та керәсең. Өйдә көләч йөзле, ачык сүзле, тәмле исле табынын тәкъдим итеп, Гөлшат каршы ала. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз дигәндәй, бу өйдә хәзрәт куллары белән ясалган рәхәтлек, матурлык. Тотрыклы тормыш алып баручы Ильяс хәзрәт милли җанлы, тәкъва хатыны өчен бөтен уңайлыкларны булдырган.

Гаилә – дәүләтнең нигезе дип күп тапкырлар ишетәбез. Ильяс хәзрәт ныклы гаилә нигезләрен, ислам кануннары буенча яшәү, гаилә башлыгының роле турында никах мәҗлесләрендә бик нигезләп аңлата. Тыңлыйсың да, ирексездән күзгә яшьләр килә, шундый дәлилләр китерә: «Бәхетле гаилә булу өчен тормыш китабы»н кулыңа алгандай чыгып китәсең.

Әле тагын шунысы кызык: авылга яучылар күп килә башлады. Хәзрәт беренче укытып чыгарган, дин гыйлеме алган инсафлы, сафлык бөркелеп торган кызларны хатынлыкка сорап, Түбән Камадан, Әлмәттән, республиканың башка районнарыннан да яучылар килеп (алтынны әллә каян эзләп табалар дигәндәй), ак кардай чиста күңелле, ак яулыклы кызларыбызны тормыш корырга яр итеп алып та китәләр. Шул парларның инде өчәр балалары бар. Әби-бабай йоласы да бик урынлы икән дигән фикергә киләм.

Без Ильяс хәзрәткә бик рәхмәтле, ул – милли һәм рухи тормышыбызның чишмәсе. Алдагы елларда да авылыбызда моңлы азан тавышлары яңгырап, мөселман кардәшләребезне Аллаһ йортына чакырып, дин сабакларын өйрәнергә, ислам диненең нигезләренә таянып, күркәм холык, гүзәл әхлак сыйфатлары тәрбияләргә, бердәмлеккә чакырып торсын. Күркәм холыклы имамыбызга Аллаһым көч-куәт, дәрт-дәрман биреп, аның исәнлек-саулык белән Аллаһыбызның безгә боерган фарызларын, тыйган хәрамнарын өйрәтүен, әхлагыбызны төзәтергә ярдәм итеп, армый-талмый эшләвен телибез.

Мәймүнә ХӘЙРЕТДИНОВА

Хыялдагы мәктәп булсын…

Безнеке дә эләккәнме? Төзекләндерү турында сүз чыкканда, әти-әниләр, иң беренче булып, үз балалары укыган мәктәпләр турында кызыксына икән. Быел федераль программа буенча республикада 66 уку йортын төзекләндерергә җыеналар. Бу хакта капиталь ремонт программаларына багышланган очрашуда Россия Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова әйтте.

– Мәгариф оешмаларын төзекләндерү – күпләрне борчыган проблема. Татарстан бу уңайдан белем йортларында шартлар тудырырга тырыша. Капиталь ремонт буенча федераль программа расланды, анда төбәкләр дә үз акчаларын куша. Уникаль программа, иминлек мәсьәләсе дә исәпкә алына. Узган ел май аенда иминлекнең никадәр мөһим булуын аңладык. Без икенче ел ашханәләрне ремонтлау буенча эшлибез. Тәмле ашату өчен ашханәдә шартлар да булырга тиеш. Узган ел 200 туклану блогы яңартылса, быел да бу эш дәвам иттереләчәк, – диде Татьяна Ларионова.

Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Станислав Андреев белдергәнчә, республикада 2012 елдан бирле бакча, мәктәпләрне капиталь ремонтлау программасы тормышка ашырыла. 2012–2020 елларда 1326 объект яңартылган. Алар арасында 785 мәктәп, 468 бакча һәм сәламәтлеге чикләнгән балалар өчен 73 оешма бар. Моның өчен барлыгы 23,7 миллиард сум акча тотылган. 2021 елда 97 мәгариф оешмасы төзекләндерелсә, быел 74е яңарыш көтә. Быелдан «Мәктәпләрдә белем бирү системасын яңарту» дәүләт программасы булдырылды. Аның буенча 14 төрле эш башкарылачак. Ремонт өчен 3,79 миллиард сум акча каралган. Шуның 1,52 миллиард сумы – республика казнасыннан. Станислав Андреев ашханәләрне, авыл җирлегендәге спорт залларын төзекләндерү программаларына да тукталды. Быел аңа 167 ашханә кертелгән. 2014–2021 елларда 130 спорт залы тәртипкә китерелгән. Быел да бу эшләр дәвам итәчәк.

Бәхетлеләр арасында Балтач районының Сосна мәктәбе дә бар. Анда хәзерге вакытта ремонт эшләре бара. 1989 елда төзелгән мәктәпнең моңа кадәр бер тапкыр да ремонт күргәне булмаган. Тугызъеллык мәктәптә 84 бала белем ала.

– Мәктәп бетсә, авыл да юкка чыга. Шуңа күрә авылда мәктәпләрне төзекләндерү – бик зур эш. Узган ел түбәсе ябылды, тәрәзә, ишекләр алыштырылды, ашханә яңартылды. Быел эчке эшләр эшләнә. Идән, түшәм, җылыту системасы алыштырыла, – диде безгә мәктәп директоры Рәшит Хәйруллин. – Мин әле – яңа директор. Моңа кадәр мәктәпнең түбәсеннән яңгыр үткән, идәнендә, диварында зур ярыклар булган. Икенче катта эшләр бетеп килә инде. Җәйгә үк башкарып чыгарга исәп. Яңа мәктәптә уку да, укыту да башка төрле. «Татнефть» 3 миллион сум акча күчерде. Шуның күпмедер өлешенә яңа парта, өстәл, шкафлар кайтачак.

Мөслим районындагы хәлләр белән дә кызыксындык. Мәгариф идарәсе башлыгының төзекләндерү эшләре өчен җаваплы урынбасары Расил Фәттахов әйтүенчә, районда өч мәктәптә ремонт узачак.

– Быел Салавыч-Мухан мәктәбенә капиталь ремонт ясыйбыз. Ул мәктәп тугызъеллык, анда 35 бала укый. Бала саны аз булса да, саклыйбыз. Тәрәзә, идәннәр алыштырыла, сыйныфлар, актлар залы яңартыла. Монда тәрәзә рамнары черегән, салкын үтә иде. Су, җылылык системасы яңача эшләнә. Шул ук вакытта ашханәләрне төзекләндерү республика программасына да керде. Моннан тыш, Михайловка, Олы Чакмак мәктәпләрендәге ашханәләр дә төзекләндерелә. Мәктәпләр танымаслык булып үзгәрәчәк, – диде Расил Фәттахов.

Капиталь ремонтка багышланган чарада Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән, милли мәсьәләләр комитеты әгъзасы, Казандагы халыкара мәктәп директоры Нияз Гафиатуллин да үз тәкъдимнәрен җиткерде.

– Диварларны яңартып кына калмыйча, ремонттан соң аларның эчтәлеген дә баетырга кирәк. Әйтик, «Татарстан могҗизалары» дигән проект булдырырга мөмкин, – диде ул.

Аның фикерләрен Татьяна Ларионова да хуплап, «Татарстан могҗизалары» проекты укучыларда ватанпәрвәрлек хисе дә уятыр иде, диде.

– Ремонт уздырылган мәктәпләрнең иҗади ягын да истә тотарбыз. Илкүләм проект кысасында меңнән артык шахмат зонасы булдырылды. Яңа җиһазлар белән тәэмин итүгә дә игътибар бирергә кирәк. Кайбер мәктәпләрдә иске парталар һаман да бар әле. Каралама урыннарына кадәр бар, болар бер дә бизәми. Ремонттан соң мәктәп хыялдагысына әйләнерлек, һәр бала, әти-әни рәхмәт әйтерлек булсын, – диде Татьяна Ларионова.

Белгечләр, ремонт эшләре 1 сентябрьгә кадәр төгәлләнеп, мәктәпләр яңа уку елына укучыларын каршы алыр дип ышандыра. Йөзен үзгәрткән мәктәпләрдә белем алу да күңеллерәк булыр.

Сәрия МИФТАХОВА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Тынычлык

Авыл урамнарында тынлык. Хәтта сәгатьләр буе карап утырсаң да, урамнан үткән бер кешене дә күрә алмыйсың. Капка төпләрендә кар таратып азапланган адәм дә юк, ихаталарда шак-шок килгән тавыш та, абзарларда мал кычкыруы да ишетелми. Хәтта җиңел машиналар да тәүлегенә бер-ике тапкыр гына узып китә. Кайчагында күңелне шом баса. Авыл өстенә ниндидер афәт килгәндер дә барлык адәми затны юк итеп бетергәндер шикелле тоела. Өрәк-авыл. Кайчагында ишегалдына ач песиләр килеп керә, анда-монда сугылып йөриләр дә, берни дә тапмагач, башларын иеп чыгып китәләр. Абзар башына чыпчыклар өере килеп куна. Чүп түгә торган урыннан нәрсәдер эзләп маташалар. Тапканы сөенә. Үз өлешен эләктереп, читкәрәк китә. Чыркылдашалар. Тавышлары матур тоела. Әллә сирәк ишеткәнгә, әллә чынлап та матур. Мин хозурланып тыңлап торам. Карыны ачса, чыпчыклар да сандугач кебек сайрый башлый икән. Келәттән бодай алып, тәлинкә белән кар өстенә куям. Тик алар сырып алырга ашыкмый, мин киткәнне көтәләр бугай. Кар тирән, авылда мал асраучылар сирәк, шулай булгач, караучысы булмаган тереклек дөньясында ачлык хөкем сөрә.

Дөньяда, илдә ниләр барганы авылда бик сизелми. Бары тик кибеткә чыксаң гына кеше күрәсең. Икмәк белән сөт кирәк иде. Икмәк – 60, сөт 90 сум тора икән. Авылда болай да бәяләр кыйммәт була. Миллионерлар яши, диярсең. Бөтен җирдә бәяләр артса да, авылда күтәрелмәс, шуннан да ныграк арттырып булмас шикелле иде. Була икән! Булдыра безнекеләр…

Хәер… Бөтен җирдә бәяләр күтәрелә бит. Бөтен әйбергә дә. Ярый, шикәр, ярма кебек нәрсәләрен аңлап була инде. Коты алынган халык аларны, чират торып, кибеттән себереп бетерде. Шул дәрәҗәдә ихтыяҗ булганда, теләсә кайсы сәүдәгәр хакларны күтәрә, табышлы булып калырга тырыша. Ләкин сәнәк, көрәк, балта кебек нәрсәләргә ул кадәр үк чират юк бит инде. Аларның бәясе дә арткан.

Әле күптән түгел генә район үзәгендә булган идем. Тимер-томыр сата торган кибетләрдә йөрдем. Бер үк кибет менә… Шунда бер үк товар… Бер кергәндә, бәясе бер төрле, икенче кергәндә – икенче. Күтәрелгән. Мин дә адәм баласы бит инде, тыелып калалмадым, кайчан да булса кирәге чыгарга мөмкин нәрсәләрнең элекке хак белән сатылганнарын җыеп кайттым. Дөрес эшләгәнмен бугай. Хәзер алар ике тапкыр кыйммәтрәк тора. Мин генә түгел инде, кулында бераз акчасы булган халык нәрсәдер алып калырга тырыша. Төрле техника, эш кораллары, электр корылмалары сата торган кибетләрнең сәүдә бармаудан зарланырлык урыны юк. Товарлар бетеп тора. Ләкин шул әйберләрне кабат кайтарту мөмкинлеге генә чикле. Кайсылары артык кыйммәтләнә, кайсылары – чит илнеке…

Офис кәгазе 1200 сумга әйләнгән. Өч тапкыр арткан! Бу инде – язучының кесәсенә турыдан-туры суга торган нәрсә. Романнар язсаң, бигрәк тә. Мәктәп укучыларының, студентларның, аспирантларның кесәсенә дә суга. Алай гына да түгел әле. Димәк, китап-дәфтәрләр дә, газета-журналлар да кыйммәтләнә дигән сүз. Документларыңны ксерокстан чыгарырга кирәк була икән, син өч тапкыр кыйммәтрәк түләргә тиеш буласың. Бер сүз белән әйткәндә, кәгазь ул бензин белән газ шикелле. Кәгазь кыйммәтләнә икән, бөтен нәрсә дә кыйммәтләнә.

Ә мин бер нәрсәгә аптырадым. Менә тимер дә, кәгазь дә кыйбатланган. Бәяләре әллә ничәшәр тапкыр күтәрелгән. Соң акча да шул тимер белән кәгазь бит инде. Тик аның бәясе төшә бара. Гаҗәп! Авыр хәлгә бирешмәү юлларын эзләгәндә: «Бөтен акчаңны биш сумлыкка әйләндереп, металлоломга тапшырсаң, отышлырак булмас идеме икән?» – дип уйлап куйдым хәтта.

Авыл халкының артык исе китми. «Бәрәңгене күп итеп утыртырбыз, кош-корт үрчетербез, – диләр. – Илләр тыныч торсын, күкләр аяз булсын инде…»

Моннан караганда, илләр тыныч… Күкләр аяз. Кояш аеруча бер ихласлык белән нурларын сибә, дөньяны яктыртып, җаннарны җылытып җибәрә. Һәм авылда тынлык… Кайчагында ишегалдына ач песиләр килеп керә, анда-монда сугылып йөриләр дә, берни дә тапмагач, башларын иеп чыгып китәләр. Абзар башына чыпчыклар өере килеп куна. Чүп түгә торган урыннан нәрсәдер эзләп маташалар. Тапканы сөенә…

Тормыш үз җаена алга бара. Табигатьтә берни үзгәрмәгән. Җанда гына бераз моңсулык бар.

Белдерү

Кадастровым инженером Кутдусовой Натальей Геннадьевной (СНИЛС № 128-830-216 57), являющейся членом СРО АКИ «Поволжье» (номер в реестре СРО: 0182, дата вступления 05.07.2013 г.) (квалификационный аттестат № 16-11-417, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1, адрес электронной почты: m2405085@yandex.ru, тел.: 8(843)2405085), подготовлен проект межевания земельных участков, выделяемых в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:16:000000:7224, расположенных по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, в границах АФ «Нокса».

Заказчиком кадастровых работ является Федулов Е.В. (тел.: 89655986986). Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования границ состоится по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1 5 мая 2022 г. в 10.30 час. С проектом межевания земельных участков можно ознакомиться по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1. Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевания и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются ежедневно с 9 до 17 часов с 4 апреля 2022 до 5 мая 2022 по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

АНА ЙӨРӘГЕНДӘ – БИШ ЯРА

Егерме ел эчендә җиде баласының бишесен һәм ире Миңһаҗны югалткан ул. Шуңа да карамастан, Арча районының Иске Кырлай авылында яшәүче 89 яшьлек Фатыйма әби Хәсәншинадан бер зарлану ишетмисең. Сынаулар өчен язмышына да үпкәләми. Аның өчен бәхет – сөенечне дә, хәсрәтне дә дөрес кабул итә белү.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Кадерле көнем»

Якты, җылы өйдә ялгызы гына яшәп ята Фатыймәттәй. Казанда яшәүче оныгы Айрат гаиләсе белән кайтып, хәлен белешеп тора икән. Баланың баласы балдай татлы булгангамы, оныгын күбрәк мактый. Иске телевизор белән күзләреңне бетермә дип, яңасын бүләк иткән. Этләр унлап тавыгын талап чыгып киткәч, әбисенә башкаларын алып кайткан. Авыр чакларында, әби хакына дип, шәһәрдән кайтып, укуын авылда тәмамлаган онык бик кадерле аңа. Авылда яшәүче кызы Миңнегөл дә, күрше авылда яшәүче Зөлфирәсе дә әнисенә булышып тора.

Моңа кадәр Фатыйма әби бәрәңгене үзе алса, узган ел күзәтеп кенә торган. Без эшләгәнне карап кына тор, дигән балалары. «Болай әйтүләрен яратмадым», – ди туры сүзле әби. Тик торырга өйрәнмәгән бит ул. Чүп утаудан туктата алмыйлар әле. Искелектә яшәсәм дә риза, дигәннәрдән түгел ул. Өч улын, ирен гүргә иңдергәч тә, бу тормыш миңа нигә хаҗәт, дип кул селтәмәгән. Өенә калай түбә яптырган. Яңа йортның эшләп бетермәгән эшләрен ахырына кадәр җиткергән. Ике ел элек мунча салдырган. Мунча керергә ярата, чистарыну борчуларын юып төшергәндәй итә.

– Бүгенге көнем бик кадерле. Иске Кырлайның ак әбисе булып яшим. Авыл халкы аркамнан сөеп китә, хәлемне белешә. Аздан да күңел була. Күршеләрем дә бик әйбәт. Күзем күрә, колагым ишетә, шулай яши алганыма шөкер, – ди ул, сөенеп.

Тәрәзә төбендә яраннар шаулап утыра. Өе ялт иткән, чисталыкны ратканы күренеп тора. Кызлар кулыдырмы бу, әбинекедерме? Ни генә дисәң дә, кадер-хөрмәттә яши.

Бер йөрәккә бит ул…

– Өч улым да туган илгә хезмәт итеп, ил каршында бурычларын үтәп үлде. Аларның Ватанга хезмәт итүләре белән горурланам. Олысы Наил Читада хезмәт итте, икенче улым Фәрит тә Читага киткән иде, аннан Монголиягә җибәрделәр. Өченче улым Илгизне Әфган сугышы вакытында армиягә алдылар. Аны озату бик авыр булды, үләр дип курыктым. «Әни, борчылма», – дип тынычландырып, Германиядән хатлар язды. Барысы да исән-сау әйләнеп кайттылар. Өч улымны гына түгел, иремне дә хәрби хезмәттән көтеп алдым. Өч ел ярым йөреп кайтты. Шуңа күрә нинди сагыну хисләре кичерүемне үзем генә беләм. Каената, каенана белән матур гомер кичердек. Әтекәй Фәтхелислам: «Килен, улым бик әйбәт хезмәт итте, аның белән бик әйбәт тор», – диде.

Өч улы да авырып үлгән аның. Аннан олы кызы якты дөньядан киткән. Гаиләсе, ике баласы калган. Ике ел элек төпчек кызы бакыйлыкка күчкән. Атын туарырга чыккан җирендә, йөрәк өянәгеннән ире күзләрен мәңгелеккә йомган. Ире үлгәнгә –19 ел.

– Бала хәсрәтләре күрермен дип кем уйлаган? Үлемнән качып котылып булмый шул. Тәкъдиреңә шулай язгач, кыска гомер белән яратылгач, беркая да китә алмыйсың. Башыңа төшкәч, җиңәсең. Авыр да, җиңел дә димәдем. Авырлыкларны хезмәт белән җиңдем. Эшләдем дә, артыма борылып карап, тагын дәвам иттем. Эш кирәк кешегә, – ди ул. – Колхозда төрле эшләр башкардым. Безнең заманда кукуруз, бәрәңге бүлеп бирәләр иде. Балалар мәктәптән туры басуга кайтты. Хәзерге яшьләр җиңел акча турында уйлый. Эшләгез, бәхетегезне табарсыз.

Үзем хуҗа

Болын кадәр өендә уллары белән сөйләшеп йөргән чаклары да була Фатыйма әбинең. Юк, саташып түгел. Хәтере яхшы әле аның. Аларның балачагын, бишек җырларын, яшь чакларын искә төшерә. Җиде балада – җиде холык. Яңартырга хатирәләре күп. Төшләренә кереп йөдәтмиләр. Дога укыгач, рухлары тынычтыр. Йокларга төнге сәгать 11–12дә генә ята. Эче пошса, саф һава сулап керә. Телевизордан яңалыкларны белеп тора, газеталар укый. Оекбашлар да бәйли. Тик анысына сарык йоны кирәк, ди. Күзлек киюне белми.

Нәселендә озак гомер кичерүчеләр юк. Әнисе 80 яшькә кадәр яшәгән. Әбекәй үзе дә йөзгә җитәрмен дип хыялланмый. Аның өчен сәламәт булганда гына картлыкның кызыгы бар. Йөгереп булмаса да, атлап йөрердәй булсын ул. Тавыклар янына чыгып, бодай сибеп, аларның йомыркаларын җыю, җылы яктан кошлар кайтканга, яшел хәтфә үләнгә сөенү… Фатыйма әби кечкенә генә нәрсәдән дә ямь таба белә.

Тиздән юбилее җитә, туксанын көтә. Балалары, оныклары, әйткәнне көтеп тормыйча, күчтәнәчләрен күтәреп кайтып җитәр. Өе тагын шау-шуга күмелер. Их, ярата инде ул шушы чакларны. Тик кунакка гына барырга яратмый. «Үз өемдә үзем хуҗа», – дип яшәргә өйрәнгән. Шушы авылда туган, шунда үскән. Башка җиргә китәсе килми.

Гаҗәп, зур хәсрәтләр кичереп тә, бер зарлану сүзе дә әйтмәде бит әбекәй. Әллә авызында кан булса да төкерергә яратмый, әллә чын-чынлап зарлана торганнардан түгел? Тик аның йөрәгендәге хәсрәтнең тирәнлеген аңлау өчен бер җөмлә җитте.

– Балаларны кабергә салу – иң зур хәсрәт. Берне түгел, бишне бит. Зират капкасын ачып кергәч, йөрәгем жу итә башлый. Бер күчтә минекеләр генә ята. Яралар кузгала, үземне «сабыр ит», дип туктатам. Каберләрен җыештырып, карап тотабыз. Кар эрегәч, тагын хәлләрен белешеп кайтырмын, – ди Фатыймә әби Хәсәншина.

Эңгер-меңгер төшсә дә, әби безне капка төбенә кадәр озатырга чыкты. «Сагынырмын сезне», – дип тә куйды. Язлар килә, тормыш дәвам итә. Яшәргә кирәк! Әбинең бу сүзләре һәммәбезгә гыйбрәт булсын иде. Ходай сабырлык бирсен сиңа, Фатыймәттәй!

Сәрия МИФТАХОВА

ҮЗ КӨЕМӘ, ҮЗ ИЛЕМДӘ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

В. П. Энгельгардт исемендәге астрономик обсерватория

✓ Яшел Үзән районы Октябрьский бистәсе.

Эш вакыты

Обсерватория: 8.00 – 17.00. Планетарий: эш көннәрендә 11.00 – 18.00, җомга 15.00 – 21.00, ял һәм бәйрәм көннәрендә 10.30 – 18.00; сишәмбе – техник көн.

Бәяләр

Обсерватория: 100–150 сум, планетарий: 350–550 сум.

Әлеге урын ел саен берничә дистә мең туристны кабул итә. Нигез ташы 1899 елда салынган бу тарихи бинаның тышкы кыяфәтенә үк битараф калып булмый. Ә эченә керсәң… галәм киңлекләренә чыктым, диярсең.

– Анда обсерваториянең эш сәгатьләрен исәпкә алып баруың хәерле. Сәфәрне бушка уздырмыйча, гаять кызыклы фильм карап, лекцияләр тыңлап кайтырга теләсәгез, билгеле. 7 яшьтән өлкән балалар өчен дә анда бару үзе бер маҗара булачак. Обсерватория территориясендә аның тарихи бинасы да бар. Биредә исә 100 еллык телескоплар саклана, – ди Русина.

Анда Казаннан 101с маршруты буенча йөрүче автобуста да барып җитәргә мөмкин.

Печищи

✓ Югары Ослан районы Печищи бистәсе.

Тау итәкләрендә XIX–XX гасырларга караган таш эшкәртү мичләре сакланган. Тау башына менсәң, киң сулы Идел, әерактарак Казан күренә.

– Анда сезон башлангач, паром белән («Аракчино – Югары Ослан» паром кичүе. – **Ред.**) барырга киңәш итәм. Гомумән, Югары Ослан кызыклы урыннарга бай. Печищи, сәүдәгәр Иван Оконишниковның данлыклы тегермәне, Соколка тавы – сокландыргыч!

Кама Тамагы

Туристлар яратып өлгергән районнарның берсе. Идел белән Чулман кушылган нокта да, Иделдән санап менгәндә, иң биек урын да, Иделнең нәкъ уртасы да Кама Тамагы районында урнашкан.

– Анда баргач, «Камский трофей»да ял итеп кайтырга киңәш итәм. Андагы манзара! Үзебездә җитештерелә торган сырдан да авыз итәргә онытмагыз. Сүз уңаеннан, монда ясалучы сырның кайбер төрләре итальяннарныкыннан һич кенә дә аерылмый. Көннәр җылыткач, сезон башлангач, виноград үстерүчеләр янында да кунак булып китегез (узган ел экскурсия бәясе бер кешегә 100 сум булган. – Ред.) Һәм, әлбәттә, Юрьев мәгарәсен дә күрми китмәгез, – дип санап китте әңгәмәдәшем.

Мин исә биеклеге 136 метрны тәшкил иткән Лабач (аны Айгыр-тау дип тә атыйлар) тавына менәргә киңәш итәм. Тарихы белән генә түгел, көче белән җәлеп итә бу мәһабәт тау.

Кама Тамагына баруның берничә ысулы бар. Машинасы булган кешегә борчыласы юк, Казаннан якынча 1,5 сәгатьлек юл. Икенче ысул – метеорда. Сезон ачылуга, көн саен 8.00 сәгатьтә Казанның елга портыннан Кама Тамагына юнәлә ул. Билет бәясе – 200 сум. Бирегә шулай ук автобуста да барып җитеп була. Тимер юл вокзалыннан Кама Тамагына автобус көн саен йөреп тора.

Зөя утрау-шәһәрчеге

✓ Яшел Үзән районы Зөя авылы.

Әлеге музей-тыюлык XVI гасыр уртасы – XX гасыр аралыгында төзелгән биналары, гаҗәеп архитектурасы, төрледән-төрле музейлары, тәмле ризыклары белән җәлеп итә.

– Самавырда кайнаган тәмле чәй, мичтә пешкән коймак… Шуның өчен генә дә барырга була! Миңа иң ошаганы – биредә «Татар бистәсе» агач археологиясе музее бар. Дөньяда мондый музейлар нибары өчәү генә – Брестагы «Берестье», Стокгольмдагы «Васа» һәм безнеке. Кызганыч, әмма Зөядәге бу музей турында күпләр ишетеп тә белми. Мин исә һичшиксез барып күрергә киңәш итәм.

Зөя утрау-шәһәрчегенә машинада, теплоход яисә автобуста барып җитеп була. Казан елга портыннан көн саен 8 сәгать 20 минутта «Казан – Зөя» теплоходы юлга чыга. Билет бәясе – 122 сум. Утрауга автобуста да барып җитәргә мөмкин, ләкин ул ял көннәрендә генә йөри. «Казан – Зөя» автобус рейсына билет бәясе – 170 сум.

Болгар

✓ Спас районы Болгар шәһәре.

Әлеге урын турында белмәүчеләр сирәктер. «Ләкин мин Бөек Болгарыбызны бу исемлеккә кертми булдыра алмыйм. Шәфәкъ вакытында яисә кояш баеганда Ак мәчетнең матурлыгын күрсәгез! Җәмигъ мәчете, Көнчыгыш, Төньяк төрбәләр, Кече манара… Санап бетерерлек түгел. Тарихи корылмалар белән беррәттән заманча музейлар да күп», – ди Русина.

vk.com

Болгарга Казаннан метеорда барып җитәргә мөмкин. Билет бәясе – 368 сум. Ләкин билетларны алдан хәстәрләргә киңәш ителә. Шулай ук борынгы шәһәргә «Южный» автовокзалыннан көнгә ике мәртәбә (10.00 һәм 17.00 сәгатьләрдә) автобус та йөри. Билет бәясе – 280 сум.

Алабуга

Рәссам Иван Шишкин, шагыйрә Марина Цветаева, кавалерист кыз Надежда Дурова бөтен дөньяга таныткан бу шәһәр дә туристларны битараф калдырмый. Җирле халыкта «Шайтан каласы» дип йөртелүче борынгы тарихи истәлек тә шәһәрдән ерак түгел.

– Бирегә берничә көнгә килергә кирәк. Мәшһүр шагыйрә Марина Цветаева музее, рәссам Иван Шишкин йорты, шуннан ерак түгел урнашкан искиткеч парк – күрерлек һәм йөрерлек урыннар күп. Бирегә килгәч, бу данлыклы сәнгать әһелләренең илһам чыганагын тапкандай буласың. Алабугада әле дә өяз шәһәрчеге рухы саклана. Монда берничә көн кунак булырга җыенасыз икән, 100 еллык тарихы булган йортта яшәү мөмкинлеге дә бар.

Алабугага барып җитүнең ике ысулы бар. Беренчесе, билгеле, машинада һәм автобуста. Икенчесен сайлаган очракта, үзегезгә уңайлы булган автовокзалдан юнәлергә була. Автобуслар анда еш йөреп тора.

Вшиха тавы

✓ Тәтеш районы үзәге.

Тәтеш үзе Иделнең уң ярында урнашкан. Аңа 1574–1578 елларда ук нигез салынган. Вшиха тавы – Иделнең уң як яр битендә урнашкан Тәтеш тауларының бер өлеше, көнчыгыштан Идел елгасы, көнбатыштан Тәтеш шәһәре, көньяктан һәм төньяктан чокырлар белән чикләнгән текә борын.

– Причал белән тау арасы – 400 баскыч биеклеге. Бу баскыч инде архитектура объектына әйләнде. Тау башында моннан 250 ел элек төзелгән каравыл манарасы урнашкан. Гомумән, Тәтеш кунакларны бик матур каршы ала. Бирегә махсус экскурсия маршруты сатып алып та килергә мөмкин (бәяләр төрле җирдә – төрлечә, якынча 2000 сумга чыга. – **Ред.**) Моннан тыш, Тәтешкә баргач, балыкчылык музеен да күреп китегез. Музей каршында биш метрлы балыкка һәйкәл дә бар. Авырлыгы 960 килолы бу балыкны моннан йөз еллап элек җирле балыкчылар тоткан. Гомумән, Тәтеш – уникаль шәһәр, – ди Русина.

Тәтешкә автобус туры белән барырга мөмкин. Бу ысулны сайласагыз, кая барыйм, ни күрим, дип аптырарга туры килмәячәк – музей хезмәткәрләре кунаклар өчен шәп программа әзерләгән. Җәй көне күпләр Тәтешкә Казанның елга портыннан юнәлүче «Казан – Болгар – Тәтеш» метеорында барып җитүне кулай күрә. Билет бәясе – 368 сум. Шулай ук Казаннан гади рейс автобуслары да йөри.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7101 данә
Гомуми тираж – 17132 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 244

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+